**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«11» 11 2021 ел Яр Чаллы № 4013

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләр прейскурантына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 30 статьясы 21 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетның 2020 елның 16 ноябрендәге 4374 номерлы карары белән расланган ТР Тукай муниципаль районы «Мэлэкэс урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. ТР Тукай муниципаль районы «Мэлэкэс урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 октябреннэн барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы А.З. Сабировка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин